| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУРАЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 октябрь, 2020 ел Мөрәле ав. № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районы Мөрәле авыл җирлегенең Зур Колангы поселогында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2020 елның 19 ноябренә 11 сәг 00 минутка Зур Колангы поселогы, Бакча урамы адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең Зур Колангы поселогында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча ***гражданнар җыенын*** билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Мөрәле авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү:

- балалар мәйданчы төзү, моның өчен материаллар, җиһазлар сатып алу;

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Зиннатуллин